Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге Башлыгы

КАРАРЫ

4 октябрь, 2024 ел № 2

Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге Кәвәл авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Кәвәл авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының Кәвәл авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 141 номерлы Кәвәл авыл җирлеге Советы карары (2021 елның 14 декабрендәге 3 номерлы, 2022 елның 12 октябрендәге 3 номерлы карарларыы белән расланган үзгәрешләр белән) нигезендә карар бирәм:

1. Кәвәл авылы җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

Гражданнар җыенын ике этапта уздырырга:

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 25 октябрендә 9 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 18А й. адресы буенча урнашкан ШЭ Саликеев А.Н. кибете янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Совет, Яшел, Пионер урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә;

- гражданнар җыенының беренче этабы 2024 елның 25 октябрендә 10 сәгать 00 минутта Үзәк урамы, 18А й. адресы буенча урнашкан ШЭ Саликеев А.Н. кибете янында. Җыенда катнашучылар исемлегенә Киров, Яңа, Мәктәп, Үзәк, Тукай урамнары буенча теркәлгән халыкны кертергә.

«Сез, 2025 елда Кәвәл торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннары, көндезге уку формасы студентлары һәм мәктәп укучылары, махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан)

азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (поселок юллары эчендә ремонт)

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Кәвәл авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Кәвәл авыл җирлеге башлыгы М.Х. Камалиев

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «КОВАЛИНСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» ПЕСТРЕЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
СОВЕТ КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ИНН 1633000857